СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«18» июль 2017 ел** **№ 135**

**Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 329 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (31.01.2017 №103,28.04.2017 № 128 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 маендагы 90 номерлы федераль закон гамәлгә керү сәбәпле, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 № 25-ФЗ Федераль законга, «Муниципаль хезмәт турында»25.06.2013 елдагы N50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына туры китерү максатларында Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 329 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә (31.01.2017 №103,28.04.2017 № 128 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24.3.Ел саен төп түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамлылыгы белән бирелә.»;

2) 24.4 пунктында «15» санын «10» санына алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 24.4.1 пункт өстәргә:

«Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен өч календарь көн озынлыгында ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев